| ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08 ноябрь, 2018 ел № 27/22

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы депутаты статусы турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2011 елның 26 маендагы 12/7 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы депутаты статусы турында Нигезнамәгә (Шәһәр Советының 2016 елның 07 апрелендәге 7/20, 2018 елның 21 февралендәге 23/12 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 4 маддәдә:

- 3 пунктның 1 пунктчасын гамәлдән чыккан дип танырга;

- 3 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«2) Шәхсән үзе яйсә ышанычлылылар аша эшмәкәрлек белән шөгыльләнү, коммерцияле оешма белән идарә итү яки аның идарәсендә катнашу (Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы идарәсеннән, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләреннән, сәяси партияләрдә, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез милекчеләр ширкәтләренең съездында (конференциясендә) яки гомуми җыелышында катнашудан башка), Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә, оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез катнашудан; муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә кую һәм идарә итү вәкаләтләрен башкару тәртибен билгеләүче муниципаль-хокукый актлар нигезендә гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә органында яйсә ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек

мәнфәгатьләрен түләүсез башкарудан, федераль законнарда каралган башка очраклардан тыш;»;

- 4 пунктта «гражданнар» сүзеннән соң «, административ» сүзен өстәргә;

2) 11 маддәдә:

- 3 өлештә «оештыру-хокукый формасына карамастан, оешмаларда һәм иҗтимагый берләшмәләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

- 5 өлештә «оешмалар» сүзеннән соң «аларның оештыру-хокукый формасына карамастан» сүзләрен өстәргә;

3) 15 маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15 маддә. Депутатның вазыйфаи затлар тарафыннан кабул ителүгә хокукы

Депутат Яр Чаллы шәһәре территориясендә үз эшчәнлеге мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары, оештыру рәвеше төрле булган оешмалар җитәкчеләре тарафыннан чиратсыз кабул ителү хокукыннан файдалана»;

4) 16 маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Депутат Шәһәр Советы каравындагы мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнарына, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларына, муниципаль предприятие һәм учреждение җитәкчеләренә язмача мөрәҗәгать итү хокукына ия.».

2. Әлеге Карар, гамәлгә керү вакыты гамәлдәге законнар белән билгеләнгән аерым нигезләмәләреннән тыш, рәсми бастырылган көннән үз көченә керә.

3. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев